СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.07.2022 г. Агрыз № 18-9

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «МНХАда ачыкланган коррупциоген факторлар турында» 2022 елның 21 апрелендәге 09/13-09/2077 номерлы мәгълүматын үтәү йөзеннән, муниципаль хокукый актны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү, дискрецион вәкаләтләр киңлеген булдырмау максатларында, «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 4 өлеше, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы, «Норматив хокукый актларның һәм хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының аерым карарларына кертелә торган кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Советының
13.07. 2022 № 18-9
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының аерым карарларына кертелүче үзгәрешләр**

**Статья 1**

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 12-3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.1.3 пунктының 5 пунктчасының беренче абзацында «Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән» сүзләреннән соң «№ 248-ФЗ» сүзләрен өстәргә;
2) 4.1.3 пунктының 5 пунктчасының икенче абзацында «Федераль закон» сүзләреннән соң «№ 248-ФЗ» сүзләрен өстәргә;
3) 4.4.3 пунктының 5 пунктчасында «(әлеге Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда» сүзләреннән соң «№ 248-ФЗ» сүзләрен өстәргә;
4) 4.5.9 пунктында «Федераль законның 21 статьясында каралган» сүзләреннән соң «№ 248-ФЗ» сүзләрен өстәргә;
5) 4.6.13 пунктында «Федераль закон белән 21 статьяның 4 һәм 5 өлешләрендә каралган тәртиптә» сүзләрен «248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә каралган тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга;
6) 4.8.2 пунктының 3 пунктчасында «Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган» сүзләреннән соң «№ 248-ФЗ» сүзләрен өстәргә;
7) 4.8.2 пунктының 4 пунктчасында «Федераль законның 90 статьясындагы 3 өлеше нигезендә» сүзләреннән соң «№ 248-ФЗ» сүзләрен өстәргә.

**Статья 2**

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 19 декабрендәге 12-5 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.1.3 пунктының 5 пунктчасының беренче абзацында «Федераль законның 95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән» сүзләреннән соң «№ 248-ФЗ» сүзләрен өстәргә;
2) 4.1.3 пунктының 5 пунктчасының икенче абзацында «Федераль закон» сүзләреннән сон «№ 248-ФЗ» сүзләрен өстәргә.».